| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | | **КАРАР** |
| 18.12.2025 | г. Казань | № 622-61/т-2025 |

Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны билгеләнешендә икътисадый нигезле тариф дәрәҗәсен, тимер юл транспорты белән «Содружество» акционерлык җәмгыяте тарафыннан пассажирлар йөртүгә тарифлар билгеләү турында

«Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» 2003 елның 10 гыйнварындагы 17-ФЗ номерлы федераль закон, «Бәяләрне (тарифларны) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы 239 номерлы һәм «Тимер юл транспорты өлкәсендә табигый монополия субъектлары эшләренә (хезмәтләренә) карата тарифларны, җыемнарны һәм түләүне дәүләти җайга салу турында» 2009 елның 5 августындагы 643 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Тимер юлда пассажирлар йөртү өлкәсендә табигый монополия субъектлары эшләренә (хезмәтләренә) карата тарифлар, җыемнар һәм түләү билгеләү (үзгәртү) мәсьәләләрен карау тәртибен, шулай ук аларны билгеләү (үзгәртү) өчен тапшырыла торган документлар исемлеген раслау турында» 2011 елның 19 августындагы 506-Т номерлы боерыгы, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Шәһәр яны билгеләнешендә гомуми файдаланудагы тимер юл транспортында пассажирлар йөртү өлкәсендә табигый монополия субъектлары хезмәтләренә икътисадый нигезләнгән тарифлар дәрәҗәсен формалаштырганда исәпкә алына торган икътисадый нигезләнгән чыгымнар дәрәҗәсен исәпләп чыгару методикасын раслау турында» 2017 елның 5 декабрендәге 1649/17 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 18.12.2025 ел, №34-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2026 елның 1 гыйнварыннан, әлеге карарның 1 нче кушымтасына ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны билгеләнешендә

тимер юл транспорты белән «Содружество» акционерлык җәмгыяте тарафыннан пассажирлар йөртүгә икътисадый яктан нигезләнгән тариф дәрәҗәсен билгеләргә.

2. 2026 елның 1 гыйнварыннан, әлеге карарның 2 нче кушымтасына ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны билгеләнешендә тимер юл транспорты белән «Содружество» акционерлык җәмгыяте тарафыннан пассажирлар йөртүгә чик дәрәҗә максималь тарифлар билгеләргә.

3. Әлеге карарның 3 нче кушымтасы нигезендә, әлеге карарның 2 нче пунктында билгеләнгән тарифларга 1,20 коэффициентын куллануны исәпкә алып, 2026 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны билгеләнешендә тимер юл транспортында «Содружество» акционерлык җәмгыяте тарафыннан «Казан – Канаш – Княжиха – Түбән Новгород – Княжиха – Канаш – Казан» маршрут юлы буенча югары дәрәҗә уңайлылык белән шәһәр яны тизйөрешле поездларында (7007/7009, 7004/7006, 7013/7015, 7022/7024) пассажирлар йөртүгә чик дәрәҗә максималь тарифлар билгеләргә.

4. Әлеге карарның 4 нче кушымтасы нигезендә, әлеге карарның 2 нче пунктында билгеләнгән тарифларга өстәмә рәвештә, 2026 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны билгеләнешендә тимер юл транспортында «Содружество» акционерлык җәмгыяте тарафыннан «Казан – Кизнер-Ижевск – Кизнер – Казан» маршруты буенча шәһәр яны поездларында (6924/6934, 6935/6925, 6926/6936, 6933/6923) югары дәрәҗәдә кулай вагоннарда пассажирлар йөртүгә чик дәрәҗә максималь тарифлар билгеләргә.

5. Әлеге карарның 5 нче кушымтасы нигезендә, әлеге карарның 2 нче пунктында билгеләнгән тарифларга 1,20 коэффициентын куллануны исәпкә алып, 2026 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны билгеләнешендә тимер юл транспортында «Содружество» акционерлык җәмгыяте тарафыннан «Казан – Кизнер – Ижевск – Кизнер – Казан» маршруты буенча кулайлык дәрәҗәсе арттырылган шәһәр яны тизйөрешле поездларында (7124/7134, 7135/7125, 7126/7136, 7133/7123) пассажирлар йөртүгә чик дәрәҗә максималь тарифлар билгеләргә.

6. 2026 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы территориясендә «Казан –Аэропорт» маршруты буенча («Казан-1» станциясеннән «Аэропорт» ахыргы станциясенә кадәр һәм «Аэропорт» станциясеннән «Казан-1» ахыргы станциясенә кадәр) шәһәр яны тимер юл транспортында пассажирлар йөртүгә максималь чик тарифны 150 сум күләмендә билгеләргә.

7. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының ««Содружество» акционерлык җәмгыяте тарафыннан гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны тимер юл транспортында пассажирлар йөртүгә икътисадый нигезләнгән тариф дәрәҗәсен, тарифлар билгеләү турында» 20.12.2024 ел, №707-64/т-2024 карарын үз көчен югалткан дип таныргга.

8. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис Р.В.Гайнетдинов

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
18.12.2025 № 622-61/т-2025
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны билгеләнешендә тимер юл транспорты белән «Содружество» акционерлык җәмгыяте тарафыннан пассажирлар ташуга тарифның икътисадый нигезләнгән дәрәҗәсе

| Т/с | Хезмәт күрсәтүнең исеме | Икътисадый яктан нигезләнгән тариф дәрәҗәсе, сумнарда |
|---|---|---|
| 1. | Тимер юл транспортында пассажирлар алып бару (дистә километрлы бер зона өчен) | 55,46 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
18.12.2025 № 622-61/т-2025
карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны билгеләнешендә тимер юл транспорты белән «Содружество» акционерлык җәмгыяте тарафыннан пассажирлар йөртүгә чик дәрәҗәдә максималь тарифлар

| т/с | Хезмәт күрсәтүнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Чик дәрәҗә максималь тариф, сумнарда |
|---|---|---|---|
| 1. | Алып бару аралыгына бәйсез рәвештә, сәфәр маршрутының беренче дистә чакрымыннан икенче дистә чакрымына кадәр бер пассажирны алып бару | 1 сәфәр | 46,00 |
| 2. | Өченчедән дүртенчегә кадәр ун километрлы зоналар буенча бер пассажирны һәр зона өчен өстәмә рәвештә йөртү | 1 зона | 36,00 |
| 3. | Бер пассажирны ул барган маршрут буенча бишенчедән сигезенчегә кадәр һәр зона өчен өстәмә рәвештә ун километрлы зоналар буенча йөртү | 1 зона | 30,00 |
| 4. | Сәфәр маршрутында тугызынчы дистә чакрымлык зонадан унөченче дистә чакрымлы зоналарга кадәр пассажирны алып барган һәр зонага өстәмә | 1 зона | 28,00 |
| 5. | Пассажир юнәлгән юл буйлап, һәр зона өчен өстәмә рәвештә бер пассажирны ундүртенче дистә километрдан башлап уналтынчы дистә километрлы зонага алып бару | 1 зона | 21,00 |
| 6. | Пассажир юнәлгән юл буйлап, һәр зона өчен өстәмә рәвештә бер пассажирны унҗиденче дистә километрдан башлап егерменче дистә километрлы зонага алып бару | 1 зона | 18,00 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
18.12.2025 № 622-61/т-2025
карарына 3 нче кушымта

Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны билгеләнешендә тимер юл транспортында «Содружество» акционерлык җәмгыяте тарафыннан «Казан – Канаш – Княжиха – Түбән Новгород – Княжиха – Канаш – Казан» маршрут юлы буенча югары дәрәҗә уңайлылык белән шәһәр яны тизйөрешле поездларында (7007/7009, 7004/7006, 7013/7015, 7022/7024) пассажирлар йөртүгә чик дәрәҗә максималь тарифлар

| Зона | Чик дәрәҗә максималь тариф, сумнарда |
|---|---|
| 1-2 | 55 |
| 3 | 43 |
| 4 | 44 |
| 5 | 36 |
| 6 | 36 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
18.12.2025 № 622-61/т-2025
карарына 4 нче кушымта

Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны билгеләнешендә тимер юл транспортында «Содружество» акционерлык җәмгыяте тарафыннан «Казан – Кизнер-Ижевск – Кизнер – Казан» маршруты буенча шәһәр яны поездларында (6924/6934, 6935/6925, 6926/6936, 6933/6923) югары дәрәҗәдә кулай вагоннарда пассажирлар йөртүгә чик дәрәҗә максималь тарифлар

| Т/с | Хезмәт күрсәтү классы | Чик дәрәҗә максималь тариф*, сумнарда |
|---|---|---|
| 1. | 1 класс | 90 |
| 2. | 2 класс | 60 |

* Әлеге карарның 2 пунктында билгеләнгән тарифларга өстәмә рәвештә кулланыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
18.12.2025 № 622-61/т-2025
карарына 5 нче кушымта

Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны билгеләнешендә тимер юл транспортында «Содружество» акционерлык җәмгыяте тарафыннан «Казан – Кизнер – Ижевск – Кизнер – Казан» маршруты буенча кулайлык дәрәҗәсе арттырылган шәһәр яны тизйөрешле поездларында (7124/7134, 7135/7125, 7126/7136, 7133/7123) пассажирлар йөртүгә чик дәрәҗә максималь тарифлар

| Зона | Чик дәрәҗә максималь тариф, сумнарда |
|---|---|
| 1-2 | 55 |
| 3 | 43 |
| 4 | 44 |
| 5 | 36 |
| 6 | 36 |
| 7 | 36 |
| 8 | 36 |
| 9 | 33 |
| 10 | 34 |
| 11 | 33 |
| 12 | 34 |
| 13 | 34 |
| 14 | 25 |
| 15 | 25 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге